**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Югары Налим авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 83** **25 ноябрь 2022 ел**

**"Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры, муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, хезмәте өчен түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмә хакында" 2019 елның 30 маендагы 139 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры, муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, хезмәте өчен түләүне оешт ыру һәм түләү шартлары турында нигезләмә хакында" 2019 елның 30 маендагы 139 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советы карары белән расланган (2020 елның 22 сентябрендәге 7 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры, муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең 2.2 пунктына үзгәрешләр кертергә, "Баш бухгалтер" һәм "Бухгалтер" юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| Баш бухгалтер | 19 700 сум | 21 000 сум |
| Бухгалтер | - | 18 500 сум |

2. Штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Карарны Татарстан Республикасының х окукый мәгълүмат р әсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **Л.И. Сибгатуллин**